**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан шәһәре **БОЕРЫК**

17.05.2021 № 549-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 30 ноябрендәге 1316-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министр-лыгының 2020 елның 30 ноябрендәге 1316-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
17.05.2021 № 549-п боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2020 елның 30 ноябрендәге 1316-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә 1.3.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.2. Министрлыкның каты файдалы казылмалар геологиясе бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоны: (843) 267-68-97. Электрон почта адресы: Svetlana.Shutnikova@tatar.ru.»;

2 бүлектә:

2.2 пункттагы «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Башкарма хакимият органы атамасы»;

2.5 пункттагы «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе»;

2.6 пункттагы «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:

Санитар саклык зонасы проектының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсе яки санитар саклык зонасы чикләренең һәм мондый зоналарда җир кишәрлекләреннән файдаланудагы чикләүләрнең санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсе (Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә).

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле документларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә дә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм аларны тапшыру тәртибе әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш»;

2.16 пункттагы «Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр»;

3 бүлектә 3.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә санитар саклык зонасы проектының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсен яки санитар саклык зонасы чикләренең һәм мондый зоналарда җир кишәрлекләреннән файдаланудагы чикләүләрнең санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсен бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә (Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсенә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза белән документлар

Министрлыкка килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

5 бүлектә:

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы 5 эш көне эчендә.»;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

5.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә»;

Административ регламентның (белешмәлек) кушымтасында «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы»

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 267-68-01 | eco@tatar.ru. |
| Министр урынбасары | 267-68-60 | Ilnur.Gubaydullin@tatar.ru |
| Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе | 267-68-95 | Aleksey.Chinarev@tatar.ru |
| Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе | 267-68-97 | Svetlana.Shutnikova@tatar.ru |
| Эшчәнлек башкару бүлеге җитәкчесе | 267-68-04<br>267-68-05 | eco@tatar.ru». |

Министр урынбасары
И.И. Гобәйдуллин ______________________________

Җир асты байлыкларыннан файдалану
мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе
җитәкчесе
С.Т. Вахитов ______________________________

Хокукый тәэминат бүлеге җитәкчесе
А.И. Ткачук ______________________________

Мәгълүмати геологик ресурслар һәм
геология тирәлеген мониторинглау
бүлеге җитәкчесе
В.Л. Полушин ______________________________

Мәгълүмати геологик ресурслар һәм
геология тирәлеген мониторинглау
бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе
С.А. Шутникова ______________________________